**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Заречный авыл җирлеге Заречный поселогы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ**

«05» ноябрь 2025 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Заречный авыл җирлеге Заречный поселогы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ**:**

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2025 елның 5 ноябрендә узган: «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Заречный авыл җирлеге Заречный поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 гр.инвалидлардан кала, балачак инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге бүлектә укучы студентлар, СВОда катнашучылардан кала, балигъ булган һәр кешедән 2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм әлеге кертемнәрне түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- урамнарны яктырту җайланмасы;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- торак пункт территориясен төзекләндерү мәсьәләсе буенча беркетмә төзелде.

Халык җыенында рәислек итүче: Л.Г. Еливанова

Заречный авыл җирлеге башлыгы Л.Г. Еливанова